**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Исполнительный комитет**
**Учаллинского сельского**
**поселения Азнакаевского**
**муниципального района**

ул. Советская, д. 51, село Учалле,
Азнакаевского муниципального
района, 423317

**ТАТАРСТАН**
**РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай муниципаль районы**
**Үчәлле авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты**

Совет урамы, 51, Үчәлле авылы
Азнакай муниципаль районы
423317

Тел./факс(885592)36-8-32; E-mail:Uchal.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от «11 » октябрь 2021 ел №18

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Үчәлле авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 29 июлендәге 12 номерлы «Агачларны кисү, кронлау, агачлар, куаклар утырту һәм күчереп утырту, газон җыю өчен рөхсәт бирү буенча административ регламентны раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Үчәлле авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Үчәлле авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 29 июлендәге 12 номерлы «Агачларны кисү, кронлау, агачлар, куаклар утырту һәм күчереп утырту, газон җыю өчен рөхсәт бирү буенча административ регламентны раслау турында» карары белән расланган, агачларны кисү, кронлау, агачлар, куаклар утырту һәм күчереп утырту, газон җыю өчен рөхсәт бирү буенча административ регламентка түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.3.1 пунктының 2 пунктчасында «агачларның, куакларның торышы турында бәяләмә белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.4.1 пунктының дүртенче абзацын төшереп калдырырга;

1.3 пунктын 2.5.4 пунктын төшереп калдырырга;

1.4. 2.6.1 пунктының 4, 5, 7 пунктчаларында «Башкарма комитет» сүзен «төзелгән килешү нигезендә муниципаль районның башкарма комитеты яисә җирле үзидарә органы» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 2.4.1 пунктының дүртенче абзацын төшереп калдырырга;

1.3. 2.5.4 пунктын төшереп калдырырга;

1.4. 2.6.1 пунктының 4, 5, 7 пунктчаларында «Башкарма комитет» сүзен «төзелгән килешү нигезендә муниципаль районның башкарма комитеты яисә җирле үзидарә органы» сүзләренә алмаштырырга;

1.5. 2.6.1 пунктының 6, 11 пунктчаларында «Башкарма комитет» сүзен «муниципаль районның җирле үзидарә органы яисә төзелгән килешү нигезендә башкарма комитет» сүзләренә алмаштырырга;

1.6. 2.6.3 пунктында «башкарма комитетның структур бүлекчәсе» сүзләрен «муниципаль районның җирле үзидарә органнары, башкарма комитет» сүзләренә алмаштырырга;

1.7. 2.8.2 пунктының 2 пунктчасында «гаризада күрсәтелгән яшел үсентеләрне тикшерү нәтиҗәсендә аеруча кирәк булган (зыян килгән) яшел утыртмаларны сүтү кирәклеген расламау» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.8. 2.8.2 пунктының 5 пунктчасында «(авария-торгызу эшләрен башкаруга яисә яшел утыртмаларны җимерүгә бәйле очраклардан тыш (агачның, зыян килгән агачларның төшү куркынычын бетерү өчен) сүзләрен төшереп калдырырга;

1.9. 2.8.4 пунктында «2 нче кушымтада» сүзләрен «3 нче кушымтада» сүзләренә алмаштырырга.»;

1.10. 3.4.2 пунктының дүртенче абзацында «, шулай ук авария-торгызу эшләрен уздыру яисә яшел утыртмаларны җимерү өчен (агачның, авария хәлендәге агачларның төшү куркынычын бетерү өчен) яшел утыртмаларны кисүгә рөхсәт алган очракта)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.11. 3.5.2.3 пунктын төшереп калдырырга;

1.12. 3.5.5 пунктында «; авария-торгызу эшләрен башкарганда яисә яшел утыртмаларны җимергәндә муниципаль хезмәт алуны сорап мөрәҗәгать иткән очракта (агачның, авария хәлендәге агачларның төшү куркынычын бетерү өчен) - ике эш көнен төшереп калдырырга» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.13. Регламентка 2 нче кушымтада «Зыян килгән агачлар кыска вакыт эчендә киселергә тиеш.» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http//aznakayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән) үз көченә керә.

Башлык Г.М.Төхвәтуллина